КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.09.2023 Казан шәһәре № 529-П

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында урнашкан, безнең эраның XIII – XIV гасырларына караган «Омар шәһәрчеге» федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясенең чикләрен һәм файдалануның махсус режимын раслау турында

2002 нче елның 25 нче июнендә гамәлгә кергән «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) турында»гы 73-ФЗ номерлы Федераль закон, 2005 нче елның 1 нче апрелендә гамәлгә кергән «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында»гы 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 нче елның 12 нче июлендәге 565 нче номерлы «Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты мәсьәләләре» карары нигезендә боерам:

1. Расларга:

әлеге боерыкка караган 1 нче кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында урнашкан, безнең эраның XIII – XIV гасырларына караган «Омар шәһәрчеге» федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясенең чикләрен (бастырылып чыгарылырга тиеш түгел);

әлеге боерыкка караган 2 нче кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында урнашкан, безнең эраның XIII – XIV гасырларына караган «Омар шәһәрчеге» федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясен куллануның махсус режимын.

2. Мәдәни мирас объектларын һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеген исәпкә алу бүлегенә, күрсәтелгән мәдәни мирас объекты территориясе чикләре турында белешмәләрне, күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына һәм Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертүне тәэмин итәргә.

3. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас
объектларын саклау
комитетының 2023 елның
15 нче сентябрендәге 529-П
номерлы боерыгына
караган 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында урнашкан, безнең эраның XIII – XIV гасырларына караган «Омар шәһәрчеге» федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясен
**кулланунын махсус режимы**

Чикләрендә археологик мирас объекты урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның махсус режимы 2002 нче елның 25 нче июнендә гамәлгә кергән «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) турында»гы 73-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә (алга таба – 73-ФЗ номерлы Федераль закон), 73-ФЗ номерлы Федераль законның 30 нчы статьясында күрсәтелгән җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләре, шулай ук гражданнарның аннан файдалана алуын, урманнардан файдалану һәм башка төрле эшләр, археологик мирас объектының сакланышын тәэмин иткән очракта башкарылырга мөмкин.

**1. Рөхсәт ителә:**

мәдәни мирас объектларын саклауның федераль органы биргән рөхсәт (ачык кәгазь) нигезендә, һәйкәлне өйрәнү эшләрен, археологик предметларны эзләү һәм алып китү максатын күздә тоткан эшләрне башкару;

мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм саклау өлкәсендә вәкаләтле орган белән килештерелгән җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен, урманнардан файдалану эшләрен һәм һәйкәл территориясе чикләрендәге башка эшләрне, яисә һәйкәлнең сакланышын тәэмин итү проектларын, йә планнаштырылган коткару проектлары нигезендә археологик кыр эшләрен үткәрү, һәйкәлнең сакланышын тәэмин итү, һәйкәлне саклап калу эшләрен башкару;

археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү шарты белән җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен, урманнардан файдалану буенча эшләрне һәм башка эшләрне башкару;

һәйкәлне музейлаштыру буенча чаралар үткәрү;

законнар нигезендә гражданнарның һәйкәлгә керү мөмкинлеген оештыру;

үләннәрне чабу, территорияне коры-сарыдан, үзлектән үсеп чыккан агачлардан һәм куаклардан чистарту.

**2. Тыела:**

мәдәни археологик мирас объекты территориясендә туфрак япмасын бозуга бәйле җир төзелеше, мелиорация, урман төзелеше, хуҗалык һәм башка эшләрне, мондый эшләрне башкару проектларында, яисә күрсәтелгән мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү проектларында күрсәтелгән, мәдәни мирас

объектының сакланышын тәэмин итү турындагы дәүләт хакимиятенең тиешле вәкаләтле органы тарафыннан килештерелгән мәҗбүри бүлекләрне гамәлгә ашырмыйча гына проектлау һәм үткәрү); коткару археологик кыр эшләрен уздыру планын, башкарыла торган эшләрнең мәдәни мирас объектына йогынтысын исәпкә алмыйча гына башкару;

туфракны, каты һәм башка көнкүреш калдыкларын, шул исәптән төзелеш калдыкларын туплап саклау;

туфракны һәм башка токымнарны алу;

чүп-чар, көнкүреш калдыкларын билгеләнгән урыннардан тыш җирләргә ташлау.